| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**17.04.2020** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 678** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия төзү турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә физик затларга субсидия бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия (алга таба – Комиссия) төзергә.
2. Комиссия составын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Комиссия турында нигезләмәне әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче М.П. Афанасьев

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 17 апрелендәге
678 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия**
**СОСТАВЫ**

| № т/б | Ф.И.О. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Нурмөхәмәтов Әмир Җәмил улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфасын башкаручы - Комиссия рәисе |
| 2. | Ибраһимов Дамир Рашит улы | «ЗМР төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ җитәкчесе урынбасары - Комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | | |
| 3. | Мөхәмәтханов Тимур Фарит улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге начальнигы |
| 4. | Стерякова Анастасия Сергеевна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм анализ бүлеге начальнигы |
| 5. | Ламбина Татьяна Михайловна | «ЗМР финанс-бюджет палатасы» МУ җитәкчесе урынбасары |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 17 апрелендәге
678 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

Комиссия субсидияләр бирү турындагы гаризаларны һәм аларга кушып бирелә торган документларны карауны гамәлгә ашыра.

Комиссиянең персональ составы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана. Комиссия әгъзалары саны-5.

Комиссия тапшырылган документларны карый һәм тапшырылган документларның, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 10 апрелендәге 641 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында, әлеге документлар кергәннән соң, 5 (биш) эш көне эчендә, бәяләмә әзерли.

Комиссия утырышы, әгәр анда 3 (өч) һәм аннан да күбрәк әгъзалар катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия әгъзалары, комиссиянең утырышында алмаштыру хокукыннан башка катнаша. Комиссия әгъзасы, утырышта булмаса, карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

Комиссия карары комиссия әгъзаларының гомуми санынннан күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Комиссия карарлары, комиссия утырышында катнашкан йә үз фикерен язма рәвештә юллаган комиссия рәисе һәм әгъзалары имзалый торган, бәяләмә белән рәсмиләштерелә.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында боерыгы мөрәҗәгать итүчегә, аны бастырып чыгарган көннән алып 3 (өч) эш көне эчендә, җибәрелә. Субсидия бирүдән баш тарту турындагы карар нигезле булырга тиеш (Нигезләмә нигезендә).

Хокук бозулар ачыкланган очракта, субсидияләрнең калган өлешләрен кире кайтарганда, Комиссия тарафыннан имзаланган акт төзелә һәм транспорт йөртүчегә(ташучыга) - субсидия алучыга тапшырыла.